“ Раслыйм”

Урта Әлки авылы “ШАТЛЫК””

балалар бакчасы” мөдире

Г.М. Ямалтдинова

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы

Урта Әлки авылы “ШАТЛЫК ” балалар бакчасы

мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең

2013 - 2014 нче уку елына эш планы.

2013 нче елның 03 сентябрендә

үткәрелгән №1 педагогик

киңәшмәдә кабул ителде.

2013 нче елның 05 сентябрендә

балалар бакчасы мөдиренең

№ 23 приказы белән гамәлгә кертелде.

## Эш планының эчтәлеге:

1. 2012 -13 нче уку елынада эшләнгән эшләргә анализ.
2. 2013- 2014 нче уку елына алынган төп бурычлар.
3. Кадрлар
4. Методик эшләр:
   - Педсоветлар;
   - Консультацияләр;
   - Методик почмакта эш;
   - Ачык шөгылләр.
5. Предметлы тирәлекне җиһазлау буенча педагогик эшчәнлекне оештыру.
6. Тәрбия эшенә җитәкчелек итү.
7. Тәрбия-белем бирү эшендә эчке тикшерү:

   -Тематик тикшерү;
   - Даими тикшерү;
   - Максатчан тикшерү.
8. Әти-әниләр белән эш.
9. Мәктәп белән эш.
10. Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар.
11. Эшчеләр белән консультация.
12. Административ – хуҗалык эше.
13. Атналыклар:
    - Саулык-зур байлык;
    - Адымнар нык, юлар имин булсын,
    - Мы учим русский язык.
14. Җәйге сәләмәтләндерү эш планы.

## 2012-2013 нчы уку елында эшләнгән эшләргә анализ

“Шатлык” балалар бакчасы Әлки районы Урта Әлки авылында урнашкан. Балалар бакчасында 7 бала тәрбияләнә.”Шатлык” балалар бакчасында бер генә төркем, ул төркемгә 1-6 яшьлек балалар керә.

2012-2013 елда укыту һәм тәрбия эше М.А. Васильева, В.В.Гербова, Т.С. Комарова методик кулланмалары нигезендә алып барылды.Бакчада үткәрелгән барлык чаралар да татар телендә үткәрелә.

Балалар бакчасында югары белемле бакча мөдире, урта профессиональ тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе эшләде һәм эшләп килә.

Уку елы буена безнең бакча экологик тәрбия эшен дәвам итүне, әхлак тәрбиясе бирү буенча һәм сөйләм телен үстерү эшен алып барды.
Балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе. Шуңа күрәдә бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларда тудырдык диярга була.Бүлмәләр якты, җылы, заман таләпләренә туры килә. Бакчада сәламәтләндерү эшләре быелгы уку елында төрле юнәлештә алып барылды. Иң беренче тәрбияче көндәлек режимны төгәл үтәп, тәрбия- белем бирү эшен дөрес оештыра. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләрен тәрбияче ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барды. Тәрбияче тәрбия-белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә җавап бирә торган прогаммалар, яңа технологияләр кулланып эшли, физкультура, иртәнге гимнастикаларда гадәти булмаган эш алымнары кулланып эшләве,балаларны чыныктыру, сәламәтләндерү эшен яхшыртырга, яхшы нәтиҗәләргә ирешергә зур ярдәм итте.

Бакчада физкультура дәресе кечкенәләр төркемнәрендә атнага ике, зурлар төркемнәренә өч тапкыр уздырылды, берсе дәреснең ачык һавада узды. Тәрбияче быелгы уку елында физкультура дәресләре уздыру буенча түбәндәге максатларны куеп эшләде:
балаларга тормышта кирәкле хәрәкәтләрне бирү;
балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көч, сәләтләрен үстерү;
сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;
балаларның үсешенә игътибар итү;
сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
заман таләпләренә туры килгән прграммалар куллану, яңалыкка омтылу.

Физкультура дәресләрендә тәрбияче иң беренче балаларның активлыгына игътибар иттә. Дәрес уздыру төрләрен үзгәртеп тордылар, яңалыклар кулланды. Балаларның сәламәтлекләрен саклап калу максатыннан тәрбияче яшь үзенчәлекләренә туры китереп, сәламәтләндерү программасы түбәндәге эш төрләрен кертеп төзеделәр:
яссытабанлыкны булдырмау, гәүдәне төз тотуга игътибар итү;
чыныктыру ысулларын куллану;
физкультура дәресләренә игътибарны көчәйтү;
гripptан саклану чараларын күрү.

Үзебезнең бакчада үскән миләш, карлыган җимешләре, яфракларын киптереп кышка әзерләп куелды. Яссытабанлыкны кисәтү, мускулларның киеренкелеген бетерү, медсестра Гайфуллина Гөлзия кызы җитәкчелегендә, тәрбияче махсус күнегүләр ярдәмендә аерым занятиеләр уздырдылыар. Тәрбияче бу күнегүләрне иртәнге. гимнастикада, физкультура дәресләрендә дә кулланды. Грипп, ОРЗ чорында медсестралар сарымсак инголяциясен даими һәр төркемгә дә ясадылар. Группа тәрбиячеләре сарымсактан төймә ясап, балаларга тактылар. Көндезге аш вакытында балаларга сарымсаклар бирелде. Билгеле, эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында, бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны бик аз булды.

Ата - аналар белән “Сәламәтлек көннәре” оештырылды, бу эшнең максаты, бурычы, ата-аналар һәм тәрбияче арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау булды.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда тәрбиячетүбәндәге рациональ гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәде:

һаваның саф булуы;
бинадагы һава температурасының тиешле дәрәҗәдә булуы;
киемнәрнең температурага карап дөрес сайлануы;
хәрәкәт режимының активлыгы.

Шушы юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналарга да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формулаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген аңлатып тордык.

Менюда ризыклар төрләндерелде, аксымга бай прдукцияләр, яшелчә, җиләк-җимешләр белән балалар тукландырылды.

Кыскасы, дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру һ.б балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте.

Балалар бакчасының төп бурычларының берсе- балалар сәламәтлеген саклау һәм ныгыту. Шул уңайдан балаларның хәрәкәт осталыкларын һәм күнекмәләрен үстерүне камилләштерү, чыныктыру уңаеннан ата- аналар белән "Күңелле старт" кичәсе оештырылды. Спорт бәйрәмнәре үткәрелде. Физик тәрбия дәресләре, иртәнге гимнастика, саф һавада йөрү, чыныктыру- төп эшләребезнең берсе булды.

Мәктәп белән ныклы элемтәдә тордык.Линейкаларда катнаштык. 1 нче сыйныфта ачык дәрестә булдык. Башлангыч сыйныф укытучыларына "Милли киемнәр" темасы буенча ачык дәрес курсәттек. Яңа ел, Әлифба бәйрәме, 9 май бәйрәмнәрендә катнаштык.

Еллык эш планы буенча һәр квартал саен ата- аналар җыелышы үткәрелде. Ата- аналар комитеты сайлау. Бакчаның яңа уку елына бурычлары һәм проблемалары белән таныштыру. Тема буенча докладлар уку, ата-аналар өчен ачык шөгел курсәтү, анкеталар тутыру,балалар белән үткәрелгән анкета нәтиҗәләре, еллык эш йомгаклары, ата- аналар комитеты отчеты.

Балаларга экологик тәрбия бирү мәсьәләсен киңәйтү өчен төрле тәрбия эшләре алып барыла. Балалар табигать почмагында гөлләрне яратып тәрбиялиләр.

Табигать почмагында- табигать байлыклары(ком, төрле ташлар һ.б булдырылды.

Ел фасылларына карап почмакта газеталар чыгарылды. Ел фасылларына бәйле үзгәрешләр, табигать кочагында үзеңне дөрес тоту, җир- суны пычыратмау , үсемлекләрне һәм җан ияләрен саклау турында балаларның белемнәре киңәйтелде. Ата- аналар, бакча балалары һәм башлангыч класс укучылары белән берлектә "Табигатьтә кунакта" кичәсе үткәрелде.

Балаларны әхлак тәрбиясе бирү максатыннан чыгып , әхлак темасына багышланган шөгыльләр, уеннар, әкиятләр алып барылды. Бу шөгыльләрдә балаларда кечкенәдән үк өлкәннәргә карата ихтирамлы булу, үз-үзеңне культуралы тоту күнекмәләрен булдыру, йөкләнгән эшне башкаруда җаваплылык хисе тәрбияләү, үзара тату уйнау һәм эшләү алымнарын булдыру өчен дә эшләдек.

Балаларның күбесе рәсем ясарга бик осталар, рәсемгә карап җөмлә төзи алалар. Диагностик тикшеренүләр мәктәпкә әзерлек төркеменең күрсәткечләре уңай нәтиҗә күрсәтте.

Балаларны мәктәпкә әзерләүгә зур игътибар бирелде. Бакчадан мәктәпкә 2 бала укырга керә.

Балаларны сүзләрдә барлык тартык һәм сузык авазларны ачык итеп әйтергә, авазларны, сүзләрне һәм гади җөмләләрне ашыкмыйча , ачык һәм аңлаешлы итеп әйтергә өйрәттек. Балаларның җөмләләрне дөрес итеп төзи белү күнекмәләрен арттырдык.Хайваннарның, кош-кортларның һәм аларның балаларының атамаларын берлек санда, күплек кушымчалары ялгап дөрес итеп әйтергә(сыер- сыерлар, чеби- чебиләр, бәбкә- бәбкәләр ,бозау- бозаулар) , рәсемнәр, иллюстрацияләр, уенчыклар буенча тәрбияче биргән сорауларга җавап кайтарырга өйрәттек.

Балаларның фикерләү сәләтен, уйлау күнекмәләрен үстерү өстендә эшләдек.

Бакча – балаларының төп шөгыле уен булганлыктан, балаларның көндәлек режимында уенга күберәк урын бирәбез. Балаларда төрле уеннар белән кызыксынучанлык тәрбияләү.Аларда рухи күтәренкелек тудыру, актив эшчәнлеккә дәртләндерү, уеены сайлаганда һәм башкарганда мөчтәкыйльлекләрен үстерү. Уен вакытында үз- үзен дөрес тотуның иң гади кагыйдәләренә буйсынырга: уенчыкларны бер- берләреннән тупас рәвештә

тартып алмаска, этешмәскә, уйнарга комачауламаска, төзегән әйберне ватмаска өйрәтү өстендә эшләдек.

Шулай ук татар халык иҗатына да зур урын бирелде. Татар халкының элек- электән килгән уеннарга , җыр – биюләренә һәм гореф- гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү эше дәвам иттерелде. “Халкыбызның күңел бизәкләре “ дигән почмак булдырылды.

Балаларны халык бәйрәмнәре белән таныштыру эшен дәвам итү. Бәйрәмнәрдә чыгышлар ясарга теләк, омтылыш булдыру. Балалар бакчасында, гаиләдә булган вакыйгаларга игътибарлы мөнәсәбәт формалаштыру. Якын кешеләргә, туган илгә мәхәббәт тәрбияләү.Көзге бал, Әниләр бәйрәме, Яңа ел, 23 нче февраль,8 нче март,Нәүрүз, Җиңү бәйрәме,Бакча белән хушлашу , балалар көне, бәйрәм иртәләре оештырылды.

Район күләмендә оештырылган “Ел бакчасы” һзм “Яшел ут” конкурсларына катнаштык.

Юл йөрү кагыйдәләренә өйрәнүгә никъ игътибар бирелә. Балаларны юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыру, транспорт төрләре, юл билгеләрен ныгыту уңаеннан “Юлда йөри беләсеңме “ дигән стенд ясалды.

Программаның эшләү анализы.

| **Шөгыльләрнең төрләре** | **2012-2013 уч.год** |
|---|---|
| Әйләнә –тирә белән таныштыру | 85% |
| Сөйләм үстерү һәм грамота өйрәтүгә хәзерлек. | 82% |
| Матур әдәбият белән таныштыру. | 83% |
| Иң гади математик күзаллауларын үстерү. | 83% |
| Сынлы сәнгать эшчәнлеге: | |
| рәсем | 83% |
| әвәләү | 85% |
| кисеп ябыштыру | 85% |
| Конструкцияләү һәм кул эше. | 84% |
| Музыка | 84% |
| Физкультура | 84% |
| Барлыгы: | 83,8% |

## 2013- 2014 нче уку елына алынган төп бурычлар.

1. “Сәламәтлек”, “Физик культьура”, “Куркынычсызлык” белем бирү өлкәләре аша балаларда сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда ата-аналар һәм балалар бакчасы бәйләнешенең үзенчәлекләре.

2. Педагогларның ИКТ компитентностен күтәрү. ИКТ не укыту -тәрбия процесында кулланышка кертү.

## 2013-2014 нче уку елына алынган төп юнәлеш .

1.Милли культураны,үз халкының рухи байлыгын өйрәнү.

## Кадрлар

| № | Ф.И.О. | Башкарган эше | Белеме | Пед. стаж | Курсл ар | Аттес тация | Катего рия | Раз ряд |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Ямалтдинова Гөлнур Мәүлетҗан кызы | Мөдир | Югары, 1998, КГПУ,ЕГФ | 21 | 2013 | 2011 | 1 | 13 |
| 2 | Гиниятуллина Нэлля Наил кызы | Тәрбияче | Махсус/ урта. 2000 | 21 | 2009 | 2011 | - | 10 |

## 1. Методик эшләр

1.1 Педсоветлар:

| № | Эш төре | срок | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1.1.1. | Т е м а : “ Яңа уку елына, яңа көч”.<br>1. Яңа уку елына әзерлекнең торышы: укыту-тәрбия программасын, һәм шуннан чыгып методик әсбаплапрны барлау; шөгыльләр бүленешен һәм көнлек режимны, эшче программаны кабул итү.<br>2. Еллык укыту-тәрбия эш планының проекты белән танышу.<br>3. УМК буенча фикер алышу.<br>Әзерлек: | Сентябрь | Барлык катнашучы педагоглар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Еллык эшне анализлау;<br>- балаларны яшь аермаларына карап төркемнәргә бүлү;<br>- яңа уку елына еллык укыту-тәрбия эше буенча еллык планының проектын төзү;<br>- УМК бунча кайткан методик әсбаплар белән куллануны дәвам итү; | | |
| 1.1.2. | Тема: Тәрбия эшендә сәламәтлекне саклаучытехнологияләр куллану.<br>1. Алдагы киңәшмәдә кабул иткән карар үтәлешенә анализ<br>2. ФДТ - сәламәтлек өлкәсенең бүгенге көн таләпләре;<br>3. Балаларның чирләп калдырган көннәренә анализ<br>4. Сәламәтлек булеге буенча проектлар белән танышу;<br>5.Балалар белән диагностика үткәрү.<br>Әзерлек:<br>- иртәнге  гимнастикаларны күзәтү;<br>- “аю табанлык”ны кисәтү масатыннын гамәлдәге җиһазларны яңарту, тулылындыру;<br>-“Саулык - зур байлык” дигән атналык уздыру;<br>- Веракса “От рождения до школы” программасынын сәламәтлек бүлекләре белән танышу;<br>- Сәламәтлек бүлегенә багышланган мероприятиеләрдән чыгып әти-әниләр өчен передвижкалар әзерләү. | Ноябрь | Барлык катнашучы педагоглар |
| 1.1.3. | Т е м а: “Тормышның куркынычсызлыгы нигезләмәләре һәм экологик тәрбия бирү шартлары”.<br>1.Алдагы киңәшмәдә кабул иткән карар үтәлешенә анализ.<br>Чыгышлар:<br>1. ФДТ- дә куркынычсызлык өлкәсенең чагылышы - тәрбиячеләр белән дискуссия.<br>2 .“Кече яшьтән балаларны урамда, җәмәгать урыннарында ничек үзләрен дөрес тотарга өйрәтергә” (үз эш тәҗрибәсеннән). | январь | Барлык катнашучы педагоглар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3.“Уеннар аша балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү”.<br><br>4. Төрлеләр.<br><br>Әзерлек:<br><br>- “Адымнар нык, юллар имин булсын!” дигән девиз астында узучы атналык үткәрү<br>- Балаларның рәсем күргәзмәсен оештыру “Ут бел<br>- ән шаярма”<br>- Куркынычсызлык – юл йөрү кагыйдәләре буен<br><br>ча уеннар өчен атрибутларны тулыландыру<br><br>- Бакча урнашкан тирә-юньнең макетын ясау<br>- Әти-әниләр өчен передвижкалар ясау:<br><br>Тема: “Бала үзе генә өйдә калса?” | | |
| 1.1.4. | Т е м а : “Балалар бакчасына заман таләбы”<br><br>1. Алдагы киңәшмәдә кабул иткән карар үтәлешенә анализ.<br><br>2. Балалар бакчасында чит тел мохите булдыру - зурлар төркемендәге ачык рус теле шөгыленә анализ.<br><br>3. Укыту-тәрбия процесында-ИКТ: сөйләм үстерү һәм рус теле шөгыльләрендә УМК – түгәрәк өстәл янында сөйләшү<br><br>Әзерлек:<br><br>- Рус теле атналыгы уздыру;<br>- тәрбиячең зурлар төркемендә рус те<br>- ле шөгылен карау;<br>- УМК әсбапларының шөгыльләрдә кулланышын тикшерү;<br>- Ата-аналар почмагында фотокүргәзмә “Безнең бакча тормышы”;<br>- Ата-аналар почмагында консультатив материал “Бала тормышында - компютер” | март | Барлык катнашучы педагоглар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1.1.5. | Т е м а: Уку елына нәтиҗә<br>1. Еллык эш планының үтәлеше;<br>2. Диагностика нәтиҗәләре (программаның бөтен бүлеге буенча);<br>3. Яңа уку елына бурычлар;<br>4. Җәйге сәламәтләндерү планын раслау.<br>5.<br>Әзерлек:<br>- Еллык эш планы үтәлешенә “Публичный доклад” әзерләү;<br>- Программаның барлык өлкәләре буенча нәтиҗә ясау өчен балаларга диагностика үткәрү;<br>- Җәйге сәламәтләндерү эш планының проектын төзү. | Май | Барлык катнашучы педагоглар |

1.2. Консультацияләр(тәрбиячеләр өчен):

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.2.1. | Документлар белән эшләү, белем бирү һәм тәрбия планнарын төзүгә таләпләр; | август | Мөдир |
| 1.2.2. | Традицион булмаган чыныктыру чаралары; | Октябрь | тәрбияче |
| 1.2.3. | Балаларда кешелек һәм әйләнә-тирә өчен куркынычсызлык тудыручы ситуацияләр турында күзаллау булдыру һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыру; | Декабрь | тәрбияче |
| 1.2.4. | Катнаш төркемдә режим вакытларын оештыру үзенчәлеге; | февраль | тәрбияче |
| 1.2.5. | Тыңлаусыз, иркә балаларны тәрбияләү чаралары; | апрель | тәрбияче |
| 1.2.6. | Сәламәтлек өлкәсенең бугенге көн таләпләре; | май | мөдир |

1.3. Методик почмакта эш:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.3.1. | Эш юнәлешләре буенча тәрбиячеләрнең портфолиоларын тулыландыру. | Ел дәвамында | тәрбиячеләр |
| 1.3.2. | Кабинетны яңа методик әсбәпләр, газета-журналлар белән тулыландырып тору. | Ел дәвамында | мөдир |
| 1.3.3. | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча альбом эшләү.<br><br>Кулланма җиһазлар булдыру. | 1 яртыел-<br><br>лыкта | тәрбияче |
| 1.3.4. | Физик тәрбия шөгыльләре өчен күрсәтмә, кулланма җиһазлар туплау. | Ел дәвамында | тәрбияче |
| 1.3.5. | Проект эшчәнлеген күзаллауга булышучы методик әсбаплар туплау. | Ел дәвамында | мөдир<br><br>тәрбияче |

1.4 Ачык шөгылләр:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.4.1. | Иртәнге гимнастиканы карау. | Ноябрь | мөдир |
| 1.4.2. | Уеннар аша балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү. | Декабрь | мөдир |
| 1.4.2. | тәрбияченең зурлар төркемендә рус теле шөгылен карау. | Март | мөдир |

## 2. Предметлы тирәлекне җиһазлау буенча педагогик эшчәнлекне оештыру

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.1. | Балада балалар бакчасына карата уңай тойгылар уяту максатыннан, төркем бүлмәләрен әзерләү (җиһазлау, төзәтү). | Июнь<br><br>Июль | Мөдир, тәрбияче |
| 2.2 | Җиһазларны балаларның яшь үзенчәлекләре буенча маркировкалау | Август | тәрбияче |
| 2.3. | Ата-аналар почмагын җиһазлау | Сентябрь | Тәрбияче |
| 2.4. | Төркемнәрне зоналарга бүлү | Сентябрь | Тәрбияче |
| 2.5. | Балаларны шәхси үсеш үзенчәлекләре буенча төркемнәргә бүлү | Сентябрь | Тәрбияче |
| 2.6. | Уен мәйданын җиһазлау буенча эш | май, июнь, | Мөдир, Тәрбияче |
| 2.7. | Баланың музыкаль сәләтен үстерү. Бергәләп концертлар, кичәләр, чаралар үткәрү. Язмалар һәм музыкаль фонограммалар куллану. | даими | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.8. | Баланың рәсемгә булган сәләтен үстерү | Даими | Тәрбияче |
| 2.9. | Балаларның сәламәтлеген саклау өчен шартлар (сәламәтлек , физкультура почмаклары җиһазларын тулылындыру) | Даими | Тәрбияче, |
| 2.10. | Үстерешле тирәлек һәм уен мохитен булдыру | Даими | Тәрбияче |
| 2.11. | Рус телен үстерү мохитен булдыру ( матур әдәбият, дидактик уеннар, фольклор, театр уеннары өчен курчаклар, видеофильмнар). | Даими | Тәрбияче |

## 3. Тәрбия эшенә җитәкчелек итү

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Тәрбиянең календарь планнарын тикшерү, анализлау, раслау. | даими | мөдир |
| 2 | Бакчаның методик эш планын раслау. | Сентябрь | мөдир |
| 3 | Шөгыльләр карау, анализлау. | Февраль | мөдир |
| 4 | Районкүләм конкурс шартлары белән таныштыру, әзерләнү. | Ел дәвамында | мөдир |
| 5 | Бәйрәмнәргә әзерлекне тикшерү, методик киңәшләр бирү. | Ел дәвамында | мөдир |
| 6 | Республика һәм районкүләм “Яшел ут ” конкурсы шартлары белән таныштыру, әзерләнү. | Ел дәвамында | мөдир |

## 4. **Тәрбия-белем бирү эшендә эчке тикшерү**

4.1 Даими тикшерү:

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Балаларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау инструкцияләрен үтәү. | мөдир |
| 2. | Сәламәтләндерү чараларының көнлек режимда чагылышы. | мөдир |
| 3. | Туклануның оештырылуы. | мөдир |

| | | |
|---|---|---|
| 4. | Көнлек режимның үтәлеше. | мөдир |
| 5. | Ата-аналар белән эшәләү алымнары. | мөдир |
| 6. | Эчке тәртип кагыйдәләренең үтәлеше. | мөдир |
| 7. | Куркынычсызлык кагыйдәләре һәм тәлапләре. | мөдир |

## 4.2. Максатчан тикшерү:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Иртәнге гимнастиканы оештыру һәм аның тәэсир итү дәрәҗәсе | Ноябрь | Мөдир |
| 2. | Төркемдәге документациянең торышы | Декабрь | мөдир |
| 3. | Туклану нормаларының үтәлеше. | Январь, май | мөдир |
| 3. | Физкультура элементлары кергән күңел ачу чараларыныңоештырылуы | Март | мөдир |
| 4. | Балаларның чирләп калдырган көннәренә анализ. | Апрель | мөдир |

## 4.3.Тематик тикшерү:

1.”Физик культура”белем бирү өлкәсендә тәрбиячененң эше.
Октябрь мөдир

## 5. Ата-аналар белән эш

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Гомүми ата-аналар җыелышлары:<br>1. - Еллык план белән таныштыру;<br>- сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү;<br>- Җәйге конкурс нәтиҗәләре;<br>- Бакчага ярдәм итүчеләргә рәхмәт хатлары тапшыру;<br>- Көзге бәйрәм концерты;<br>2. Уку елы йомгаклары:<br>- “Яшел ут кагыйдәләре”;<br>- Җәйге чыныгу кагыйдәләре”<br>- Анкета “ Сез балагызны беләсезме”;<br>- Актив ата-аналарга рәхмәт хатлары, дипломнар бирү; | Сентябрь<br><br><br><br><br>Май | Мөдир,<br>Тәрб.-е<br><br><br><br>Мөдир,<br>Тәрб.-е |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Ата-аналар почмагында еллык эш планына нигезләнеп<br><br>материалларны яңарту | Ел дәвамында | Тәр.-е |
| 3. | Консультацияләр:<br>- “Балам сәламәт үссен дисәң”;<br>- “Бала үзе генә өйдә калса?”;<br>- “Бала тормышында - компютер” | <br>Октябрь<br>Январь<br>Март | <br>Тәр.-е<br>Тәр.-е<br>Тәр.-е |
| 4. | Зурлар төркеме балалары, әти-әниләр катнашында ЮЙК буенча спорт бәйрәме. | Январь | Тәр.-е |
| 4. | Ата-аналар почмагында фотокүргәзмә “Безнең бакча тормышы”; | Февраль | Тәр.-е |

## 6. Мәктәп белән берлектә эш

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Башлангыч класс укытучылары белән берлектә эш планы төзү:<br>а)1 класс һәм зурлар төркеменең программа таләпләрен чагыштыру;<br>б) узган уку елында 1 классны тәмамлаган балаларның уку күрсәткечләре белән танышу, фикер алышу; | Сентябрь | мөдир |
| 2. | Экскурсияләр һәм максатчан прогулкалар:<br>- “Белем бәрәмендә”катнашып 1 класска кергән иптәшләрен тәбрикләү;<br>- 1 класс кабинеты белән танышу;<br>- Башлангычларның рус теле дәресләрендә катна-<br>шу . | <br>Сентябрь<br><br>Ноябрь<br>февраль | <br>Тәр.-е<br><br>Тәр.-е<br>Тәр.-е |
| 3. | Башлангычлар белән берлектә эшләр:<br>- Мәктәпнең театр атналыгында катнашу;<br>- “Тукай абый әкиятләре” - Г.Тукайның туган көненә багышланган уртак кичә оештыру. | <br>Декабрь<br>Апрель | <br>Тәр.-е<br>Тәр.-е |

## 7.Бәйрәмнәр һәм күңел ачулар

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | - “Ак яулыклы әбием” -өлкәннәр көне уңаеннан бәйрәм иртәсе | Октябрь | |
| 2. | “Көзге муллык ” | Ноябрь | |
| 3. | “Кышкы урманга сәяхәт” | Декабрь | |
| 4. | Әтиләребез җитез, без шаяннар һәм өлгер” Спорт бәйрәме | Февраль | |
| 5. | “8 Март бүген” | март | |
| 6 | -“Тукай абый әкиятләре”-әкияти кичә | Апрель | |
| 7. | Кече Сабантуй | Июнь | |

## 8.Эшчеләр белән консультацияләр

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | “Бакчаның хезмәтне саклау буенча эчке тәртип кагыйдәләрен беләсеңме?” | сентябрь | Мөдир |
| 2. | “Бакчада электр приборларының кулланышына игътибарлы бул!”. | октябрь | Мөдир |
| 3. | “Сәламәт тәндә-сәламәт акыл”. | ноябрь | Мөдир |
| 4. | “Яңа ел бәйрәме уздыру буенча техник куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтә!”. | декабрь | Мөдир |
| 5. | “Кышкы чорда балалрның тормыш именлеген, сәламәтлекләрен саклау барыбызның төп бурычы”. | январь | Мөдир |
| 6. | “СанПиНның кагыдәләрен искә төшерик”. | февраль | Мөдир |
| 7. | “Балалар бакчасы- синең икенче йортың”. | март | Мөдир |
| 8. | “Бакчаның тышкы матурлыгы, бар хезмәткәрнеңдә җаваплылыгында”(субботник-лар, чәчәк рассадалары утырту, агачлар утырту һ.б.). | апрель | Мөдир |

## 9. Административ-хуҗалык эшләре.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Гомуми җыелышлар:<br>1. а)“Бакчаның хезмәтне саклау буенча эчке тәртип кагыйдәләрен беләсеңме?”<br>б) Көзге бакча эшләрен кыска срокларда тәмамалау мәсәләсен карау.<br>2. а) уку елына йомгак ясау | Сентябрь<br><br>Май | Мөдир<br><br>Мөдир |
| 2. | Тарификацияне вакытында һәм кыска срокларда үтү. | Сентябрь | Мөдир |
| 3. | Балалар бакчасының МТБ ын ныгыту өстендә эшләүне ныгыту  максатын-<br>нан , смета төзү өчен документлар тапшырып, финанс мөмкинлеклр булган очракта, эшне гамәлгә кертү өстендә эшләү. | Октябрь | Мөдир |
| 4. | Продукция һәм арзан материаллар отчетларын, хезмәт-<br>кәрләрнең эшләгәнһәм балаларның килгән көннәрен<br>барлау ведомостьларын вакытында бухгалтериягә тап-<br>шырып бару. | Ел дәвамында | Мөдир |
| 5. | Отпусклар графигын эшләү | Январь | Мөдир |
| 6. | Арзан һәм тиз тузучан материалларны гамәлдән чы-<br>гару, инвентарьларныисәпкәалу комиссияләре эшенә<br>уңай җирлек тудыру. | Декабрь-<br>апрель | Мөдир |
| 7. | Кышкы чорда бакчага килүче юлларны кардан чистар-<br>туны тәэмин итү. | Декабрь-<br>март | Мөдир |
| 8. | Бакча һәм авыл территориясен язгы чистарту эшләрен-<br>дә катнашу. | Апрель | Мөдир хезмәткәрләр |
| 9. | Агымдагы ремонт эшләре | Август | Мөдир |

*Кушымта №1*

## “Саулык – зур байлык” – сәламәтлек атналыгының эш планы

Максат: Балаларда сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру.

Үткәрү вакыты: ноябрь.

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Проект “Мин мин икән, мин кем икән”. | Атнаның беренче көне |
| 2. | Иртәнге гимнастиканы карау. | Атнаның икенче көне |
| 3. | Балаларның рәсем күргәзмәсе “Әти-әни, мин – спорт гаиләсе” | Атнаның өченче көне |
| 4. | Зурлар төкемендә әңгәмә: “Дару үләннәре” | Атнаның дүртенче көне |
| 5. | Ике төркем белән бергә “Кечкенә спорт бәйрәме” | Атнаның бишенче көне |
| 6. | Ике төркем белән бергә сюжетлы-ролле уен “Шифаханә” | Атнаның алтынчы көне |

*Кушымта №2*

## “Адымнар нык, юллар имин булсын!” дигән девис астында узучы атналык эш планы.

Максат: урамнарда һәм юлларда үзеңне хәвефсез тоту күнекмәләрен үстерү.

Оештыру вакыты: Январь

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Әңгәмә “Машина һәм светофор” –зурлар төркеме | Атнаның беренче көне |
| 2. | “Шофер булырга телим” җырын өйрәнү. | Атнаның икенче көне |
| 3. | “Юл аҗаганы” күңел ачу  кичәсе – зурлар, кече яшьтәгеләр катнашында. | Атнаның өченче көне |
| 4. | “Мин юлчы”дигән темага балалар эшеннән күргәзмә. | Атнаның дүртенче көне |
| 5. | Зурлар төркеме балалары, әти-әниләр катнашында ЮЙК буенча спорт бәйрәме. | Атнаның бишенче көне |

*Кушымта № 3*

## “Мы учим русский язык” план недели русского языка в средней группе.

Тема: “Мы учим русский язык”.

Задачи: формирование первоначальных умений и навыков практического владения русским языком в устной форме. Воспитывать интерес, любовь и уважение к русскому языку. Быть проводниками детей  в мир двуязычья. Время проведения: февраль 2013год.

| | | |
|---|---|---|
| 1 | “Мы дружные ребята” (стихи, потешки, считалки, сказки) | Первый день недели |
| 2 | “Учимся играя”(игры разных народов) | Второй день недели |
| 3 | “Зима-зимушка зима” (коллективное рисование) | Третий день недели |
| 4 | Экскурсия в школу (встреча с первокласниками и с учителем начальных классов) | Четвертый день недели |
| 5 | “На поляне детства” музыкальное развлечение | Пятый день недели |

*Кушымта № 4*

## Җәйге сәламәтләндерү планы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Җәйге чорга инструктаж | Май | Мөдир |
| 2 | Хезмәт коллективының җыелышы, җәйге сәламәтләндерү кампаниясенең бурычлары | Май | Мөдир<br>Тәрбиячеләр |
| 3 | Эшчеләрне беренчел ярдәм күрсәтү методларына өйрәтү (травмалар, агуланулар, зарарлы бөҗәкләр тешләве) | Май | ФАП тан шәфкатъ туташы |
| 4 | Санитар һәм гигиена таләпләре буенча, кояш һәм һава ванналары кабул итү өчен мәйданчыклар әзерләү | Даими, җәйнең азагына кадәр | Тәрбиячеләр, тәрбиячеләрнең ярдәмчеләре, |
| 5 | Юл кагыйдәләрен беркетү буенча ата – аналар катнашы белән гамәли шөгыльләр уздыру. | Июнь | Тәрбиячеләр |
| 6 | “Сабантуй – 2014”, “1 июнь – балаларны яклау көне.” | Июнь | Мөдир, тәрбиячеләр, ата-аналар |
| 7 | “Табигать - туган йортыбыз” дигән темага ата-аналар белән сөйләшү. | Июнь | Тәрбиячеләр |
| 8 | Чәчәкләр бәйрәме | Июль | Тәрбиячеләр |
| 9 | Рәсемнәр күргәзмәсе | Июль | Тәрбиячеләр |
| 10 | Җәйге спартакиада | Июль | Тәрбиячеләр |
| 11 | Өстәмә туклану | Даими | Мөдир |
| 12 | Шифалы үләннәр җыю | Җәйнең азагына кадәр | Бөтен коллектив һәм ата-аналар |